УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссиясе составына үзгәрешләр керту турында

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы һәм 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Ә.М. Мазһаровны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Аршинов Виктор Петровичны – Россия Рәссамнәр берлегенең Татарстан Республикасындагы бүлеге рәисен (килешү буенча);

Сәлахов Мәкъзүм Хәлимулла улын – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президентын (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 ел, 02 март
№ ПУ-196